**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5100**
**06.10.2020**

Башкарма комитетның 2013 елның 31 июлендәге 4542 номерлы карары белән расланган торак урынны торак булмаган урын һәм торак булмаган урынны торак урын итеп күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 31 июлендәге 4542 номерлы карары (Башкарма комитетның 2014 елның 11 апрелендәге 2165 номерлы, 2016 елның 28 июнендәге 3321 номерлы, 2018 елның 28 апрелендәге 2395 номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 7501 номерлы, 2019 елның 14 июнендәге 3044 номерлы, 2019 елның 9 августындагы 4087 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган торак урынны торак булмаган урын һәм торак булмаган урынны торак урын итеп күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6 пунктның икенче баганасындагы 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүматларны үз эченә алган);»;

2) 3.3.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат аша яки КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша, муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача яисә электрон рәвештә гариза бирә һәм әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны Башкарма комитетка тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон рәвештә Башкарма комитетка электрон почта яки Интернет-кабул итү аша җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Гаризаларны теркәүне Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе гамәлгә ашыра, аннан соң документлар алга таба эшләү өчен идарәгә тапшырыла.»;

3) 3.4.1. пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында гомуми файдаланудагы мәгълүматларны үз эченә алган);».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов